| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

«14 » ноябрь 2015 ел Олы Кайбыч ав. № 14

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2015 елның 5 октябрендәге 285-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итү һәм мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар күрү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Кайбыч муниципаль районы Советы карар кылды:

I. Кайбыч муниципаль район Советының 2012 елның 28 апрелендәге 112 номерлы (Кайбыч муниципаль район Советының 2012 елның 14 августындагы 128 номерлы, 2013 елның 28 гыйнварындагы 150 номерлы, 2014 елның 27 февралендәге 205 номерлы, 2014 елның 29 июлендәге 231 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяның 5.5 өлешендәге 11 пунктында «үзенең турыдан-туры начальнигы» сүзләрен «яллаучы (эш бирүче) вәкиле" сүзләренә алмаштырырга;

2) 8 статьяда:

а) 8.1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.1. Әлеге Нигезләмә максатлары өчен «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән «мәнфәгатьләр конфликты» төшенчәсе кулланыла.»;

б) 8.2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.2. Әлеге Нигезләмә максатлары өчен «коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән «шәхси кызыксыну» төшенчәсе кулланыла.»;

в) 8.2.2 өлештә "акцияләр белән", һәм «, акцияләр», сүзләрен төшереп калдырырга.

II. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Законлылык, регламент һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

**Совет рәисе,**
**Кайбыч муниципаль**
**районы Башлыгы** **А.И.Рәхмәтуллин**